| СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.07.2024 г. Агрыз № 38-6

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 елның 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.04.2024 елның 290 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга (15.12.2022 елның 23-5 номерлы карары редакциясендә).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 01.07.2024 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз гамәлләрен җәелдерә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының "11" 07 2024
елның 38-6 номерлы карары
белән расланды
(15.12.2022 елның 23-5
номерлы карары редакциясендә)

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр**

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 26.10.2022 елның 20-8 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - карар):

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әгерҗе муниципаль районы башлыгына, Әгерҗе муниципаль районы башлыгының урынбасарына, Әгерҗе муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенә ай саен акчалата түләү билгеләргә:

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район башлыгы | 35272 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 31745 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 31745 |

1.2. Карарның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органында билгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи оклад билгеләргә:

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 34640 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 31176 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 31443 |
| Башкарма комитет эшләре идарәчесе | 29178 |

| | |
|---|---|
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 31043 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 28512 |
| Совет, Башкарма комитет һәм җирле үзидарәнең башка органы бүлеге башлыгы | 24248 |
| Совет, Башкарма комитет һәм җирле үзидарәнең башка органы бүлеге башлыгы урынбасары | 21184 |
| Башкарма комитет һәм җирле үзидарәнең башка органы секторы мөдире | 19585 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, район башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 21184 |
| Советның, башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органының баш белгече | 18786 |
| Советның, башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органының әйдәп баручы белгече | 17454 |

1.3. Карарның 6 пунктындагы 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.